**ГЛАВА СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422729, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Суксу, ул. Школьная, 9А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9А

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**25 март 2024 ел** **№1**

## Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Чәмәк торак пунктында авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге Федераль законның 25.1, 56 статьяларына ярашлы № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе, нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Чәмәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 05.04.2024 елга билгеләргә. Үткәрү вакыты 10 сәгать 00 минутта. Утырыш урыны: ТР, Биектау районы, Чәмәк авылы, Кооператив урамы, 9 нчы йорт каршында.

1.1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлегенең Чәмәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 23 октябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы: «2024 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Биектау районы Суыксу авыл җирлеге Чәмәк торак пунктында теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

"Чәмәк торак пунктына вак таш җәю;)

2023 елның 23 октябрендәге 1 номерлы карарда күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эшләргә үзгәртү:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Чәмәк торак пунктына вак таш җәю)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев